**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** — **РЕШЕНИЕ**

**25 ноябрь 2022 ел** — **№ 59**

## Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 нче елның 7 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 нче елның 15 нче октябрендәге 7 нче номерлы карарына (2018 нче елның 4 нче маендагы 81 нче номерлы Совет карары редакциясендә), түбәндәге эчтәлекле 3.2 пункты өстәп үзгәрешләр кертергә:

«Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 нче елның 21 нче сентябрендәге 647 нче номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән Россия Федерациясе гражданнары мөлкәтенә салымны түләүдән азат итәргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Бу карар 2021 нче елның салым чорында физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ф. Хисаметдинов